…ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СЫЗЫП АК НУР БЕЛӘН!

# Караш


1999 нчы елның 19 нчы маеннан чыга.
№ 2 2014. Октябрь-ноябрь
«НӘШРИЯТ ЭШЕ» түгәрәге

## МӘСКӘҮ: ЕРАК АРАЛАРНЫ ЯКЫН ИТЕП...

Хисләнеп җыр тыңлап утырган вакытта миңа смс килде: “5-9 ноябрь көннәрендә Мәскәү шәһәренә экскурсия була.Барырга теләгең булса әйтерсең миңа” диеп язылган иде анда.Мин әлеге хәбәр турында дус-кызларым белән фикерләшкәч, бер барырга булдым, бер юк. Аз гына вакыт узгач, әти-әниемә җиткердем. Әни белән әти риза булдылар, үземнең генә әле барасы килсә, әле шикләндерә иде. Җавапны төгәл әйтү вакыты килеп җитте. Мине дустым Миләүшә барырга күндерде. Аннары инде без Раилне дә барырга күндердек. Лашманнан өчәү барабыз булды. Без ничә көн рәттән Мәскәүдә ничек кызык булачагын сөйләштек. Артык нык көтергә ярамый диләр дә, ярый ник ярамасын. Без дә нык көттек, бик нык.

Җыену көне бик дулкынландыргыч иде.Нәрсә алып барырга белмәү, барыргамы юкмы турында икеләнү, каникулга читтәге дуслар кайтуы... Чынлап та болар бар да күңелдә ниндидер бер аңлатып булмаслык хисләр уята иде. Бару көне. Әлеге көндә күңелдә булган хисләр үземә дә аңлашылмый әле. Барам кебек тә түгел иде.Таныш шәһәргә генә барып кайтам кебек иде. Ләкин әлеге хисләр бик тиз үзгәрде,яңа дуслар белән танышу, поездда вакытны кызык үткәрү, хәтта җитәкче апабызнын орышуы да мактау кебек ишетелә иде.

Сәгать иртәнге 6 нчы яртыларда килеп җиттек без. Безне гид каршы алды. Иртән иртүк Мәскәүне карый башладык. Күңелдә булган хисләәр,тойгылар... Искиткеч иде анда. Мәскәүдә таң ата, нинди матур күренеш. ”Воробьевы горы” да булдык, томан иде..Барсы да бик якшы күренмәде, ләкин алдагы көннәрдә без барсын да карадык. ”Красная площадь”тагы куренеш бик тә матур иде.Үз илебезнең тарихын тыңларга бик кызык иде, горурланып тирә-якны күзәтү дә узенчә тойгылы иде.Кунакханәгә барып урнашу, күпме көтеп торулар бик тә арытты арытуын, тик ул шуңа тора иде..



Кызыл мәйданның тышындагы күренеш



Иске Мәскәү күренеше

*(дәвамы 2 нче биттә)*

*БУ АЙДА...предмет олимпиадаларының район туры башланып китте. Мәктәп туры җиңүчеләренә Лашман мәктәбе данын яклап район турында чыгыш ясарга туры килә. Биремнәр бик катлаулы. Барысына да уңышлар телибез!*

*БУ АЙДА... 20 нче ноябрьдә 11 нче сыйныф укучылары рус әдәбиятыннан сынау шартында инша яздылар. Ә 3 нче декабрь көнендә аларга чын сынау тотарга туры киләчәк.*

*БУ АЙДА... 9 нчы сыйныф укучылары математика һәм рус теленнән мониторинг үттеләр. Нәтиҗәләр түземсезлек белән көтелә. Бик, бик зур түземсезлек белән...*

*БУ АЙДА... 19 нчы ноябрьдә Чистай шәһәрендә үткән К. Тимбикова исемендәге регионара фәнни-эзләнү укулары булып узды. Анда Нуретдинов Ислам, Саматова Айгөл һәм Газимзянова Ранияләр чыгыш ясады.*

*БУ АЙДА... 24 нче ноябрьдә Казанда “Илһамлы каләм” конкурсы булып узды. Безнең мәктәптән Галимова Алсинә һәм Билялов Тимербулат бу конкурсның җиңүчеләре.*

*БУ АЙДА... тагы бик күп күңелле вакыйгалар булып узды, төрле спорт ярышлары. Алары турында алдарак!!!*

## МӘСКӘҮ: ЕРАК АРАЛАРНЫ ЯКЫН ИТЕП...(башы 1 нче биттә)

Һәр көн яңа экскурсия булды. Күпме чит яктан килүчеләр иде Мәскәүдә. Искиткеч күп. Һәрбер бина ниндидер тарихка бай. Олимпиадалырга төзелгән высоткалар,ярыш узу биналары бик матур иде. Картиналар галереясына кердек, 62 бүлмә тулы картиналар иде.Алар шундый үзенчәлекле,һәрберсе үз тарихын сөйләделәр. Чиркәүләрне карадык,аларнын төзелеше,бизәлеше башка сыймаслык иде, элегрәк хәзер булган приборлар да булмаган бит, ә шундый искитәрлек ясалган алар. Элекеге күренешләр сурәтләнгән панорамада булдык, ишелгән, янган өйләр, үлгән атлар, бәрелгән шлемнар бар да сугыш ахырын сурәтли иде. Кино төшерелә торган урында булдык. Иске Мәскәү сурәтләнгән урамнар ясалган анда.

Яза башласаң язып бетермәслек, һәрбер бина узенә бертөрле төзелгән бит анда.Искиткеч шәһәр Мәскәү, кайтырга теләк бөтенләй дә юк иде.Булса да якыннар янына гынадыр.Тирәнтенрәк өйрәнергә теләк уянды, үз тарихыннны белү зур горурлык икәнлеген аңладым, горурланырлык илдә яшәвемә ышандым.

Әлеге экскурсияне оештыручы Динмухаметова Галия апага һәм Елена Дмитриевнага аеруча да зур рәхмәт!

*Ләйлә Шәйхетдинова 10 нчы А сыйныфы укучысы*

## ШИГЪРИ ПОЧМАК

*Акка төренеп, тагын кыш килер...*

*Акка төренеп, тагын кыш килер,*
*Урамнар тагын акка әйләнер...*
*Күп тә үтмәс, бу ак падишаһ*
*Күмеп калдырыр безнең җирләрне.*
*Күз кәннәрендә, төнлә ул килеп,*
*Карлар яудырган...*
*Безне җәй буе кыш та сагынган...*
*Юеш көннәрдә зарыгып беттек,*
*Хоккей уйнарбыз дип*
*Кышны без көттек.*
*Җыелып бергә*
*Тауга чыгарбыз,*
*Шаулашып бергә*
*Чаңгы шуарбыз!!!!*

**Нуретдинов Ислам.**
**8 нче сыйныф укучысы**

## 28 НЧЕ НОЯБРЬ – ӘНИЛӘР КӨНЕ



Ана – ул дөньяда иң бөек кеше. Бөтен күренекле шәхесләрне, галимнәрне, укытучыларны, табибларны ана тудырган. Ана баланы тугыз ай буе үзенең карынында күтәреп йөртә, тудыра, бала тугач, ул аңа үзенең күкрәк сөтен имезеп, төн йокыларын калдырып үстерә. Кичләрен баласына бишек җырлары җырлый, әкиятләр сөйли...

Әни... Кеше үз гомерендә шул сүзне ничәмә-ничә кабат әйтә икән? Әйткән саен яңадан-яңа мәгънә алып килә. Бу сүз аша ана синең йөрәгеңне күрә. Без әниләребезгә үзебезнең яратуыбызны күрсәтү өчен аларга мәрхәмәтле, миһербанлы булырга тиешбез. Әнием! Биргән киңәшләрең тормыш иткәндә юлдаш булсыннар иде. Рәхмәт, әнием, барысы өчен дә зур рәхмәт!

**Нуретдинова Наилә.**
**6 нчы сыйныф укучысы**

## МИНЕМ БУШ ВАКЫТЫМ –МИНЕМ СӘЛАМӘТЛЕГЕМ.

***Көзге каникуллар вакытында "Чирмешән" физкультура-савыктыру комплексы бассейнында дүрт районнан 120 яшь йөзүче көч сынашты.***

***БЕЗНЕКЕЛӘР ИКЕНЧЕ!!!***

8 нче ноябрьдә район үзәгендәге спорт комплексы бинасында йөзү буенча ярышлар булып узды. Бу ярышларга дүрт районнан йөзүчеләр катнашты: Мөслим, Алексеевск, Яңа Чишмә, Чирмешән командалары үзара көч сынашты. Барлык катнашучылар килгәч, ярышны ачу тантанасы булды. Тантанада гимнны яңгыраткач, баш судья Билялов Фаиз абый ярышның максаты, узу тәртибе белән таныштырды. Һәркем тырышты. Ярышның оештыру моментында бигрәк тә безнең Лашман мәктәбенең өлкән сыйныфларында укучы кызлар зур ярдәм күрсәттеләр.




Безнең район данын Чирмешән лицее һәм Лашман мәктәбе укучыларыннан торган җыелма команда (тренеры Фаиз Билалов) яклады. Алар арасыннан Елена Ерошкина һәм Инсаф Дәүләтшин брасс стилендә йөзүдә үз яшьтәшләре арасында финишка беренче булып килделәр.

Ярышның җиңүчесе булып Мөслим районы спортчылары танылса, чирмешәнлеләр кискен көрәштә икенче урынга чыкты. Яңа Чишмә районы командасы өченче урында. Республика укучыларының Х спартакиадасына әзерлек кысаларында узган әлеге бәйге җиңүчеләрен кубоклар һәм грамоталар белән бүләкләделәр.

**Мигманова Алинә. 6 нчы сыйныф укучысы**

**"Караш" газетасының әлеге саны өчен җаваплы: Газимзянова Р. Ф.**
**Хәбәрләшү өчен телефон: 9270444015**